СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» апрель 2023 ел № 74

Салымның вакытында түләнми калган өлешен (недоимка), җирле салымнар буенча пеняларны һәм штрафларны түләттерүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктка туры китереп һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Урта Көшкәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча вакытында түләнми калган өлешен (недоимка), әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар бурычын (алга таба - бурыч) түләттерүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- бурыч барлыкка килү вакыты өч елдан артык булган очракта, вафат булган физик затларның бурыч;

- вафат булганнан соң 6 ай эчендә мираска хокук белдерелмәгән очракта, вафат булган физик затларның бурыч;

- түләттерүгә ышанычсыз бурыч барлыкка килү датасы киләсе айның һәр 1 числосына өч елдан артык булган бурыч;

- әгәр суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлеген тәмамлау турында карар чыгарылуга бәйле рәвештә салым органнары тарафыннан бу бурычны түләттереп булмаган очракта, бөлгенлек (банкротлык) турында эштә кулланыла торган процедураларда булмаган салым түләүчеләрнең бурычы;

- салым түләүчеләрдә 2022 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча бурыч;

- бурычлы кешенең бурыч хисабына алырлык мөлкәте булмаганда, аны түләү бурычы барлыкка килгән мизгелдән алып 3 елдан артык вакыт узганда, Россия Федерациясеннән киткән физик затларның бурычы.

2. Җир салымы һәм физик затлар мөлкәтенә салым буенча бурычларны түләттерүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып түбәндәгеләр тора:

физик затның яшәү урыны буенча салым органының салымның вакытында түләнми калган өлеше (недоимка), пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

физик затларның граждан хәле актларын теркәүне гамәлгә ашыручы органның физик затның үлеме фактын теркәү турында белешмәләр;

мираска хокук турында таныклык бирү хакында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе.

3. « Салымның вакытында түләнми калган өлешен (недоимка), җирле салымнар буенча пеняларны һәм штрафларны түләттерүгә һәм исәптән чыгаруга ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2019 нчы елның 21 октябрендәге 119 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип таныйрга.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет-ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы Перфилов Ю.М.